**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлеге Илюткино авылы торак пункты гражданнар җыены КАРАРЫ**

«01» ноябрь 2024 ел № 8

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Бикүле авыл җирлеге Илюткино авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Би Күле авыл җирлегенең Илюткино авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан тыш, балачак инвалидларыннан тыш 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пункт территориясен төзекләндерү.

Халык җыенында рәислек итүче А.М.Шакирова

Би Күле авыл җирлеге башлыгы А.М.Шакирова